ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Минзәлә муниципаль районының «Коноваловка авыл җирлеге» һәм «Иске Маҗын авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 19 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Минзәлә муниципаль районы составына керүче «Коноваловка авыл җирлеге» һәм «Иске Маҗын авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен әлеге Законга кушымта нигезендә үзгәртергә.

**2 статья**

«Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2005, № 1 (IV өлеш); 2008, № 11 (I өлеш); 2010, № 5 (I өлеш); 2014, № 11 (IV өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Минзәлә муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм
аларның статусы турында» Татарстан
Республикасы Законына
1 нче кушымта

## «Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре **карта-схемасы**




Шартлы билгеләр:

- -Татарстан Республикасы чиге
- -муниципаль район чиге
- 10 -тоташу ноктасының тәртип саны
- 10 -җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- -торак пунктлар
- -муниципаль районның административ үзәге
- -җирлекнең административ үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 17 (19) – 16 (А) | -Удмурт Республикасы |
| 16 (А) – 1 (67) | -Әгерҗе муниципаль районы |
| 1 (67) – 31 (68) | -Тукай муниципаль районы |
| 31 (68) – 33 (69) | -Сарман муниципаль районы |
| 33 (69) – 25 (70) | -Мөслим муниципаль районы |
| 25 (70) – 17 (19) | -Актаныш муниципаль районы |

«Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге
составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Минзәлә шәһәре |
| 2 | Әтрәкле авыл җирлеге |
| 3 | Аю авыл җирлеге |
| 4 | Бикбау авыл җирлеге |
| 5 | Югары Тәкермән авыл җирлеге |
| 6 | Воровский авыл җирлеге |
| 7 | Иркәнәш авыл җирлеге |
| 8 | Кадрәк авыл җирлеге |
| 9 | Коноваловка авыл җирлеге |
| 10 | Хуҗамәт авыл җирлеге |
| 11 | Наратлы Кичү авыл җирлеге |
| 12 | Николаевка авыл җирлеге |
| 13 | Яңа Мажын авыл җирлеге |
| 14 | Яңа Мәлкән авыл җирлеге |
| 15 | Тауасты Байлар авыл җирлеге |
| 16 | Иске Мажын авыл җирлеге |
| 17 | Иске Матвеевка авыл җирлеге |
| 18 | Ырыс авыл җирлеге |
| 19 | Юртово авыл җирлеге |
| 20 | Юшады авыл җирлеге |

»;

2) 11 нче кушымтаның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Коноваловка авыл җирлеге чиге Иске Мажын авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 12 нче тоташу ноктасыннан алып, Ашпала елгасын һәм кибеп баручы инешләрне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 3,5 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 100 м төньяк-көнбатышка таба агач-куаклык үсемлекләре массивы буйлап бара, аннары 100 м төньяк-көнбатышка таба агач-куаклык үсемлекләре массивы буйлап бара, шуннан соң 100 м көньяк-көнбатышка таба, текә ярны ике тапкыр кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 150 м төньяк-көнбатышка таба агач-куаклык үсемлекләре массивы буйлап бара, 150 м көнбатышка таба, текә ярны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 50 м агач-куаклык үсемлекләре массивы буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, төньяк-көнбатышка таба 100 м агач-куаклык үсемлекләре массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буенча бара, шуннан

соң, сынык сызык ясап, 100 м көньяк-көнчыгышка таба буа буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, текә ярны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 600 м көньяк-көнбатышка таба, 150 м көньяк-көнчыгышка таба, 550 м көнбатышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 250 м көньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 50 м агач-куаклык үсемлекләре массивы буйлап, көньяк-көнбатышка таба 450 м агач-куаклык үсемлекләре массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, агач-куаклык үсемлекләре массивын һәм «Мәскәү – Уфа» – Тупач автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м сазлыкның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 700 м көньяк-көнбатышка таба һәм, Минзәлә елгасын һәм сазлыкны кисеп үтеп, 800 м көньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң, текә ярны һәм кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 450 м көньяк-көнбатышка таба, «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Минзәлә участок урманчылыгындагы 184 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 20 м уза, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, әлеге аерымланган кишәрлекнең көнбатыш чиге буйлап 800 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 30 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 300 м төньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң 184 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап 650 м көньяк-көнчыгышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң урман массивы буйлап 20 м көньякка таба уза, 119 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап 100 м төньяк-көнчыгышка таба бара, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 700 м, «Мәскәү – Уфа» – Тупач автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Тупач елгасын кисеп үтеп, 150 м агач-куаклык үсемлекләре массивы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 199 нчы урман кварталының һәм 124, 125, 126 нчы урман кварталларының аерымланган кишәрлекләренең төньяк-көнбатыш чиге буйлап 4,8 км уза, аннары, сынык сызык ясап, 126 нчы, 128 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 4,3 км уза, 129 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 350 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 129 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 700 м төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, умарталык буйлап көньяк-көнчыгышка таба 150 м, 129 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 150 м уза, шуннан соң 129 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 700 м һәм көньяк чиге буйлап 600 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 700 м, 129 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап 200 м уза, текә ярны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 750 м чокыр төбе буйлап, 850 м көньякка таба буа буйлап, Тупач елгасы агымы буенча 1,3 км өскә таба Коноваловка, Иске Маҗын һәм Юшады авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тупач авылыннан 1,6 км көньяк-көнчыгышта Тупач елгасында урнашкан 29 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.»;

3) 18 нче кушымтаның тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Иске Мажын авыл җирлеге чиге Коноваловка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 12 нче тоташу ноктасыннан алып, Ашпала елгасын һәм кибеп баручы инешләрне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 3,5 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 100 м төньяк-көнбатышка таба агач-куаклык үсемлекләре массивы буйлап бара, шуннан соң 100 м көньяк-көнбатышка таба, текә ярны ике тапкыр кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 150 м төньяк-көнбатышка таба агач-куаклык үсемлекләре массивы буйлап бара, 150 м көнбатышка таба, текә ярны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 50 м агач-куаклык үсемлекләре массивы буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, төньяк-көнбатышка таба 100 м агач-куаклык үсемлекләре массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буенча бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 100 м көньяк-көнчыгышка таба буа буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, текә ярны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 600 м көньяк-көнбатышка таба, 150 м көньяк-көнчыгышка таба, 550 м көнбатышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 250 м көньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 50 м агач-куаклык үсемлекләре массивы буйлап, көньяк-көнбатышка таба 450 м агач-куаклык үсемлекләре массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, агач-куаклык үсемлекләре массивын һәм «Мәскәү – Уфа» – Тупач автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м сазлыкның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 700 м көньяк-көнбатышка таба һәм, Минзәлә елгасын һәм сазлыкны кисеп үтеп, 800 м көньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң, текә ярны һәм кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 450 м көньяк-көнбатышка таба, «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Минзәлә участок урманчылыгындагы 184 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 20 м уза, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, әлеге аерымланган кишәрлекнең көнбатыш чиге буйлап 800 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 30 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 300 м төньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң 184 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап 650 м көньяк-көнчыгышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң урман массивы буйлап 20 м көньякка таба уза, 119 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап 100 м төньяк-көнчыгышка таба бара, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 700 м, «Мәскәү – Уфа» – Тупач автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Тупач елгасын кисеп үтеп, 150 м агач-куаклык үсемлекләре массивы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 199 нчы урман кварталының һәм 124, 125, 126 нчы урман кварталларының аерымланган кишәрлекләренең төньяк-көнбатыш чиге буйлап 4,8 км уза, аннары, сынык сызык ясап, 126 нчы, 128 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап

көньяк-көнбатышка таба 4,3 км уза, 129 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 350 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 129 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 700 м төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, умарталык буйлап көньяк-көнчыгышка таба 150 м, 129 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 150 м уза, шуннан соң 129 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 700 м һәм көньяк чиге буйлап 600 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 700 м, 129 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап 200 м уза, текә ярны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 750 м чокыр төбе буйлап, 850 м көньякка таба буа буйлап, Тупач елгасы агымы буенча 1,3 км өскә таба 29 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.


Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН *

Казан, Кремль
2018 ел, 08 декабрь
№ 97-ТРЗ

«Минзәлә муниципаль районының «Коноваловка авыл җирлеге» һәм «Иске Мажын авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең  һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына кушымта

## «Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре
## <u>карта-схемасы</u>




Шартлы билгеләр

-муниципаль берәмлекләр чикләре

-А-Б Коноваловка авыл җирлегенең һәм Иске Мажын авыл җирлегенең чиктәш чиге

-Минзәлә муниципаль районының Коноваловка авыл җирлеге территориясе составына кертелә торган Минзәлә муниципаль районының Иске Мажын авыл җирлеге территориясе

-җирлекләрнең административ үзәкләре

-торак пунктлар